Татарстан Республикасы Азнакай районы газетасы

**Җомга** №67 (13646) 16 сентябрь 2022 ел

# МАЯК

Газета 1930 елның 15 мартыннан чыга 16+

Яңалыкларны **www.aznakaevo-rt.ru** сайтында һәм социаль челтәрләрдәге төркемнәребездә укыгыз


## Грипп якынлаша: аннан ничек сакланырга?

**АКТУАЛЬ**
"Маяк" газетасында узган чираттагы "Түгәрәк өстәл" сөйләшүе дә әлеге мөһим темага багышлады. /3


Михаил Захаров

## Шөпшәләр белән көрәш

**ЯШӘЕШ**
Мин эштән кайтып кергәндә, веранда өчен барган сугышның иң кызган чагы иде... /6



Илдар Динмөхәммәтов:

# "Укытучысы яхшы булса, укучысы аны узар"



Табигатьтә ял итү – зур эшләргә рухландыра./ФОТО: МИРСӘЛИМ ГАТАУЛЛИН АРХИВЫННАН - 5 БИТ

Яңалыклар



## Көзге ярминкәгә килегез

**Районыбыз халкын үз җирлегебездә җитештерелгән экологик чиста, арзанлы азык-төлек белән тәэмин итү максатыннан уздырылган авыл хуҗалыгы ярминкәләре дәвам итә.**

Бу атнаның шимбәсендә, ягъни 17 сентябрь көнне 9.00 сәгатьтә шәһәрнең "Шифа" каршында һәм Актүбә бистәсенең базар мәйданында чираттагы ярминкә үтәчәк. Анда ит, сөт, ярма, он, яшелчә, бөртекле культуралар, бал һәм башка авыл хуҗалыгы продукциясе сатылачак. 0+

## Мәктәп олимпиадалары башланды

**21 сентябрьдән Бөтенроссия һәм республика олимпиадаларының мәктәп этабы башланды.**

Укучылар Бөтенроссия олимпиадасыннан 24 фәннән, алардан тыш 15 фәннән республика олимпиадасында белемнәрен сынаячак.

Узган уку елында олимпиадаларның мәктәп этабында 30 фәннән 8815 укучы катнашкан. Муниципаль этапка үткән 1460 укучының 489 ы җиңүче и призер булган, 76 сы республика һәм ил югарылыгында бәйге тоткан.

## "Маяк"ка ташламалы бәядән язылып калыгыз!

**2023 елның икенче яртыеллыгына "Маяк" газетасына язылуның кызган чагы. Ярты елга язылу бәясе – 849,42 сум.**

Ә 3-13 октябрьдә ташламалы бәядән – 742,74 сумга язылырга мөмкин булачак. Бу 107 сум акчагыз янга кала дигән сүз.

Редакциядә язылу буенча альтернатив пункт та эшли. Бу очракта газетаны биредән килеп алырга кирәк булачак. Язылу бәясе – 480 сум. Күпләп язылган оешма-предприятиеләргә илтеп бирү мөмкинлеге дә бар.

Киләсе ел башыннан район газетасы өегезгә килеп торсын дисәгез, хәзердән үк язылып куярга ашыгыгыз. Алга таба да бергә булыйк – бердәм булыйк!

16+ Реклама

# Сөт – хуҗалыкның табыш чыганагы

Авыл хуҗалыгы

**Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең оператив мәгълүматлары буенча районда тәүлеклек савым 154675 кг тәшкил итә (һәр сыердан уртача 18,3 кг), бу узган елның шушы чорына караганда 13 мең кг артыграк.**

Иң күп сөт җитештерүче – "Союз-Агро" җәмгыяте – 93180 кг. Бирредә көнгә һәр сыердан 23,9 кг сөт савалар. "Азнакай" агрофирмасында тәүлеклек савым – 33930 кг (һәр сыердан 15,4 кг).

"Таллы Буләк" хуҗалыгы сөтчелек тармагы буенча шулай ук әйдәп бара – бер сыерга тәүлеклек савым 18, 5 кг туры килә (көнлек савым 3700 кг).

– Җитәрлек күләмдә терлек азыгы әзерләдек. Компьютерда программалаштырылган махсус җиһазда (миксерда) килограммын килограммга туры китереп, төрле азыктан баланслаштырылган туклыклы катнашма ясала һәм сыерларга билгеләнгән күләмдә генә таратыла. Ризык та әрәм булмый, сыерлар да җитәрлек күләмдә витаминлы азык ала һәм сөт күләме дә бермә-бер арта, – ди хуҗалык җитәкчесе Наил Мотыйгуллин.



Фото: Лилия Миннеханова
И.Габидуллина КФХда алыштыргысыз савымчы

Илзирә Габидуллина крестьян-фермер хуҗалыгы да ел ярымга җитәрлек терлек азыгы әзерләгән. Анда көнлек савым һәр сыердан 16,4 кг тәшкил итә.

– Урып-җыю эшләрен уңышлы тәмамладык. Фермалар ремонтланган. Көннәр матур торгач, әле маллар җәйләүдә, тиздән утарларга кайтарабыз, – ди тормыш иптәше, уң кулы Илшат Габидуллин.

Хуҗалыкларда төп табыш сөтчелектән керә. Юкка гына сөт сыерның телендә димиләр.

– Барлык хуҗалыклар да артыгы белән терлек азыгы әзерләде. Бүгенге көндә безнең бурыч – малларны дөрес тукландырып, мул продукция алу, уңышлы кышлату, – ди авыл хуҗалыгы һәм азык төлек идарәсе җитәкчесе Рамиль Исламов.

**Резеда ШӘРИПОВА**

# Иң яхшы комбайнерлар

***"Нью-Холланд" комбайнында***

Азат Галәүетдинов, "Марс" ЖЧҖ – 4508 т

Әсгать Бикмөхәммәтов, "Тукай" ЖЧҖ – 3394 т

Рәзил Шакиров, "Агросила-Логистика" ЖЧҖ – 2720,7 т

Айдар Фазлиев, "Агросила-Логистика" ЖЧҖ – 2658,4 т

Фазыл Әхәтов, "Агросила-Логистика" ЖЧҖ – 2652,1 т

Раушат Мостафин, "Агросила-Логистика" ЖЧҖ – 2611,2 т

Мәгадәт Мөхәмәтов, "Агросила-Логистика" ЖЧҖ – 2390,5 т

***"Акрос" комбайннарында***

Рамил Сәхапов, "Агросила-Логистика" ЖЧҖ – 3314,9 т

Инсаф Мияссәров,"Тукай" ЖЧҖ – 3152,5 т

Илдар Хәйруллин, "Марс" ЖЧҖ – 3142 т

Урал Шәехов, "Агросила-Логистика" ЖЧҖ – 2948,1 т

***"Торум" комбайнында***

Илнар Садыков, "Агросила-Логистика" ЖЧҖ – 3117,9 т

Илгизәр Ганиев, "Агросила-Логистика" ЖЧҖ – 2913,4 т

Рәсим Мөхәмәдиев, "Агросила-Логистика" ЖЧҖ – 2708 т

***КЗС комбайнында***

Илшат Габидуллин, "И.И.Габидуллина" КФХ – 2756 т

# Штраф та түлисең, җәяү дә йөрисең

Хәвефсезлек

**Узган атнада җәмәгать судьялары тарафыннан РФ Җинаять Кодексының 12.26 маддәсе буенча 2 эш каралып, исерек хәлдә машина йөртүчеләргә карата административ җәза билгеләнде.**

Исерек килеш машина руле артына утыру – җинаятькә тиң булса да, районыбызда атна саен спиртлы эчемлекләр кулланган 5-6 шофер кулга алына.

Соңгы көннәрдә генә җәмәгать судьялары тарафыннан эчкән килеш руль артына утыручылар белән бәйле 5 эш каралып, юл иминлегенә куркыныч тудыручылар тиешле җәзага тартылды.

24 августта төн уртасында эчкән килеш машина белән идарә иткән И.Миннебаев та үз җәзасын алды. Ул медицина тикшерүеннән дә баш тарткан була. Судта ул үзенең гаебен тулысы белән таный, үкенүен белдерә.

Азнакайлы Р.Ситдиковны хокук сакчылары Мәскәү-Уфа юлында кулга төшерә. Ул шулай ук тикшерүдән баш тарта, суд утырышына килеп торуны да кирәк санамый.

Р.Гобәйдуллинны юл-паструль хезмәте вәкилләре Шәйхетдинов урамында туктата. Судка ул килми.

Исерек килеш машина белән идарә иткән В.Гыйльмановны инспекторлар төнге өчтә Солтангалиев урамында эләктерә. Судта ул үзенең гаебен тулысы белән таный.

22 июльдә Мәсгут авылы урамы буйлап машинада хәрәкәт иткән Л.Самарцева да хокук сакчылары игътибарыннан читтә калмый. Тикшерү барышында ул үзенең гаебен таный, үлгән туганын искә алу чарасында ярты стакан вино, тынычландыра торган дарулар эчүен әйтә. Аның тәрбиясендә өч кечкенә баласы булуны суд әлеге эш буенча йомшарту шартлары буларак кабул итә.

Юл йөрү кагыйдә-таләпләрен бозган өчен аларның барысы да 30 мең сум штрафка тартылып, ел ярымга машина йөртү хокукыннан мәхрүм ителәләр.

# Ишегалды бәйрәме күңелле узды

Авылым минем

**Сукаеш авылында чираттагы ишегалдын ачу тантанасы узды, анда «Безнең ишегалды» республика программасы кысаларында территорияне төзекләндерү буенча эшләр башкарылды.**

Бәйрәм чарасына олылар һәм балалар да күпләп килгән иде. Бу очрашуда район Советы аппараты җитәкчесе Айдар Хәлиуллин да катнашты.

Ул сукаешлыларны сәламләп, аларның хезмәттә дә, көнкүрештә дә бердәмлеген билгеләп үтте, мондый чараларның дустанә атмосфера тудыруда мөһимлеген ассызыклады.

Авыл үзешчәннәре барлык катнашучыларга да күтәренке кәеф бүләк иттеләр. Бу көн барлык кунаклар һәм тирә-як йортларда яшәүчеләр күңелендә кайнар алкышлар, якты елмаюлар һәм яхшы кәеф белән истә калды.



Программа кысаларында йорт ишегалдында балалар мәйданчыгы, асфальт юл һәм тротуар, автомобильләр өчен парковка барлыкка килде. Ишегалды үзгәрде, балалар бүген мәйданчыкта рәхәтләнеп уйныйлар, олылар төзекләндерелгән территориядә ял итәләр.

# Ришвәткә урын юк

Актуаль

**Бүгенге тормышыбызның тискәре күренешләреннән берсе - ул ришвәтчелек. Кешеләр сәламәтлеген кайгырткан медицина учреждениесендә аңа урын бигрәк тә булмаска тиеш.**

Бу нәүбәттән район үзәк сырхауханәсендә даими һәм максатчан профилактик эшчәнлек алып барыла. Медицина персоналы белән төрле чаралар, җыелышлар үткәрелгәндә бу тема беркайчан да читтә калмый.

Шунысы куанычлы, коррупциянең җитди очраклары булганы юк. Табиблар, шәфкать туташлары һәммәсе үз вазифаларына җаваплы карап, коллективта тискәре күренешләргә юл калдырмыйлар.

Әйе, һәркемгә үз сихәтлеге кадерле, пациентларның да үзләрен үлемнән алып калган, вакытында дөрес диагноз куеп нәтиҗәле дәвалау үткәргән шәфкать ияләренә рәхмәтләрен ирештерәсе килә. Әмма моның иң дөрес ысулы - чын йөрәктән чыккан рәхмәт сүзе, хөрмәт хисләре. Табиблар, шәфкать туташларына ихластан белдерелгән рәхмәт иң кадерле бүләк, хезмәтләренә югары бәя. Шулай булганда, бернинди ришвәтчелеккә юл куелмас.

**Әнәс Гәрәев, район үзәк сырхауханәсенең коррупциягә каршы көрәш комиссиясе секретаре**

# Чарасын алдан күрик

Грипп якынлаша

**Ел да көз-кыш белән бергә ишекләребезне грипп та шакый башлый. Быел гына искәрмә булмас анысы, белгечләр дә грипп якынлашуы турында чаң кага. Бу төр авыруларны булдырмый да калып була. Әлбәттә, моның иң яхшы ысулы – гриппка каршы вакытында вакцина ясату. Ләкин аны көзен үк – сентябрь-октябрь айларында ясату мәслихәт.**

“Маяк” газетасында узган чираттагы “Түгәрәк өстәл” сөйләшүе дә әлеге мөһим темага багышланды. Анда район үзәк сырхауханәсе баш табибының эпидемиология мәсьәләләре буенча урынбасары Светлана Ибраһимова, район үзәк сырхауханәсенең медпрофилактика кабинеты мөдире Луиза Морадымова, район педиатры Илһамия Гыйниятуллина, инфекция бүлеге мөдире Гөлнар Шәйдуллина, табиб-методист Роберт Каһарманов катнаштылар.

Бүген районыбызда гриппка каршы прививка ясату тулы куәтенә бара. Вакцина бернинди куркынычсыз һәм ышанычлы. Быел көз районда гриппка каршы вакцинациягә 16 меңнән артык кешегә үткәрү планлаштырыла.

Гриппка каршы вакцинаның бары тик грипптан гына саклавын да билгеләп үтәргә кирәк. Башка төрле салкын тию чирләренә каршы профилактик чаралар куллану, алардан саклану һичшиксез кирәк.

Аннары, вакцина иммунитетны киметә, чирләтә, диган фикер дә һич дөрес түгел, ди табиблар. Аны ясаткан кеше тирә-юньдәгеләргә дә бернинди зыянсыз.

– Иммунизация өчен иң кулай чор – сентябрь, октябрь айлары, чөнки эпидемия башлангач кына аны ясатуның файдасы юк. Практика күрсәткәнчә, ОРВИ һәм гриппның иң баш калкыткан чоры гыйнвар, февраль айларында күзәтелә. Районда ул барлык медицина учреждениеләренең прививка ясату кабинетларында, амбулаториядә һәм фельдшер-акушерлык пунктларында бушлай ясала. Үзвакытында ясатылган прививка эпидемия вакытында чирләп китү ихтималын 1,5-2 тапкырга киметә, – ди Светлана Ибраһимова.

Ел саен бу төр авыруларның 70 процентка якыны балалар өлешенә туры килә икән. Бу исә аларга профилактик прививканың тиешле күләмдә ясалмавын күрсәтә.



– Монда төп гаеп нарасыйлары сәламәтлегенә зур куркыныч яналуын аңламыйча, аларга прививка ясатудан баш тарткан әти-әниләрдә. Узган елгы сезонда да авыручыларның вакцина ясатмаган булулары ачыкланган. Сырхауханәгә бик авыр хәлдә китерелгән балалар бар, бу вакытта әтиәниләр терсәкләрен тешләр дәрәҗәгә җитә дә, әмма инде соң була, – ди Илһамия Гыйниятуллина.

Сүз дә юк, грипптан саклану чаралары турында белеп торырга тиешбез. Вакцина ясатылды дип тынычланып калмаска, ә организмны ныгыту ягын да карарга кирәк.

**– Сәламәт яшәү рәвеше алып бару шулай ук төрле вируслар йоктырудан саклый. Кеше үзен сәламәт хис итсен өчен тиешенчә йокларга, аксымнарга бай продуктлар ашарга, минераль матдәләр, витаминнар күбрәк кулланырга, физик активлыкны арттырырга тиеш. Шәхси гигенаны сакларга: кулларны даими юып, бүлмәләрне җилләтеп, сөртеп торырга кирәк, – ди Луиза Морадымова.**

Соңгы елларда барыбызны да үз кубызына биеткән коронавирус беркая да китмәде. Аннан да прививка ясату мәслихәт.

– Районыбызда аның “омикрон” штаммы күзәтелә. Күп очракта авыру җиңел үтә, әмма җиңел уза дип уйларга кирәкми. Ул – шактый җитди авыру, үзеннән соң барыбер начар эз калдыра. Авыр очраклар да күзәтелә, аларны Яр Чаллының йогышлы авырулар сырхауханәсенә җибәрәбез. Атнага аларның саны 2-3 булып тора. Бу гадәттә хроник авырулары булган кешеләр (шикәр диабеты, симерү, үпкә, йөрәк авырулары). Практика күрсәткәнчә, аларның берсе дә прививка да ясатмаган була. Быел моның өстенә грипп эпидемиясе дә көтелә. Монда бары тик прививка гына саклаячак, – ди Гөлнар Шәйдуллина.

Районга яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинаның борынга тамыза торганы да кайткан.

Назаль вакцина ике компонентлы, беренчесеннән соң өч атна узгач, икенчесе кертелә. Табиблар фикеренчә, борынга кертелә торган вакцина – ревакцинация өчен иң кулае. Ә беренче тапкыр вакцинация узучыларга аны инъекция рәвешендә кадату киңәш ителә.

Белгечләр ике прививканы бер көндә үк ясатырга да мөмкин булуын да искәртә.

БАНК ЗЕНИТ

**ДЛЯ НАС КАЖДЫЙ КЛИЕНТ – ЗВЕЗДА!**

Мы ценим деньги наших клиентов и не тратим их на безумные гонорары приглашенных звезд
**zenit.ru**




**ПАО Банк ЗЕНИТ.** Ген. лицензия Банка России №3255 от 16.12.2014. Реклама.

**8 (800) 500 66 77 или *0667**

## Теләкләрнең иң изгесе сезгә, кадерлеләребез!



1233 Октябрь Бүләк авылында туып-үсеп, хәзерге көндә Азнакай шәһәрендә гомер итүче тормыш иптәшем, әниебез, яраткан әбиебез ***Корбанова Венера Фәхртдин кызының*** олы юбилее. Моңсу күзләргә ямь өстәргә теләгәндәй, табигатьнең шушы мизгелендә 75 ел элек дөньяга килеп, син барлык туганнарыңны сөендергәнсең.

Кешене бәхет тудырмый, үз бәхетен кеше үзе ясый. Син бәхетеңне үзең коеп, ireңә, балаларыңа, туганнарыңа да өлеш чыгардың, һәрвакыт якты йөзең, тәмле сүзләрең белән каршы алганың өчен рәхмәт сиңа. Алдагы гомер юлларыңны шулай ук сау-сәламәт, күтәренке кәеф һәм туган-тумачаларың, якыннарың белән бәхетле көннәрдә үтәргә язсын сиңа.

**Иң изге теләкләр белән, сине яратып: тормыш иптәшең Хәмбәл, балаларың, оныкларың**

*Әнкәй, диеп әйтер кешең булу*
*Нинди бәхет бит ул дөньяда.*
*Шатлыкларың булса – уртак була,*
*Кайгыларың булса югала.*
*Уйлама әле картаям, дип,*
*Шат-көләч бул, сүнмә-сүрелмә.*
*Кадер-хөрмәт күреп үтсен гомерең,*
*Урыннарың булсын гел түрдә.*


*Котлы булсын туган көнең,*
*Озак яшә, бул син бәхетле.*
*Яныбызда син булганда гына*
*Табып була олы бәхетне.*
*Шатлык белән яшә, хәсрәт күрмә,*
*Тыныч булсын һәрчак күңелең.*
*Бәрәкәтле матур тормыш сиңа,*
*Кояшларга тиңе гомернең.*

Шушы көннәрдә кадерле әтиебез ***Корбанов Хәмбәл Әхәт улы*** да туган көнен үткәрде!

Кадерле әтиебез! Балаларың, оныкларыңның бәхетенә, уңышына куанып, әниебез белән озын-озак яшәргә язсын сиңа. Бәйрәмең котлы, мөбарәк, бәхетең түгәрәк булсын.

Гомерләрең озын булсын синең,
Бәхетләрең булсын гомерле.
Белеп яшә балаларың, оныкларың өчен җирдә
Син иң изге һәм иң кадерле!

**Иң изге теләкләр белән:**
**тормыш иптәшең Венера**
**һәм балаларың**



## Йөрәк сүзе – йөрәккә!

1368 23 сентябрьдә газиз туганым ***Гомәрова Миннегөл Арслангали кызына*** 70 яшь тула. Туганым Миннегөл! Сине зур юбилееӊ белән тәбрик итәбез! Корычтай сәламәтлек, бәхетле озын гомер телибез. Син бит безнең иң изге, иң чиста күңелле, иң гадел туганыбыз. Үзеңнең сәламәтлегең бик ныклы булмаса да, мине -93 яшьлек әбиеңне сабый бала урынына һич авырыксынмыйча тәрбиялисең. Аллаһы Тәгаләнең мең-мең рәхмәтләре яусын үзеңә. Авырлыклар күрмичә, рәхәт яшә! Үз изгелекләрең меңе белән үзеңә кайтсын! Амин!



*70 яшең белән котлап,*
*Зур бәхетләр сиңа телибез.*
*Үзең кешелекле булган өчен,*
*Олылыйбыз бүген сине без.*

**Иң изге теләкләр белән: туганнарың, Зәйтүнә әбиең, Дания туганың, энең Раиль**

## Күркәм юбилейларыгыз белән!

1367 Урманай авылында яшәүче Максудов Риф Газиз улына 23 сентябрьдә һәм Максудова Флера Фәррах кызына 25 сентябрьдә 80 яшь тула. Сәламәтл[illegible]ләр һәм якты киләчәк телибез.



*Зур бүләкләр алып бирер идек,*
*Тик аларның сезгә тиңе юк.*
*Теләкләрнең кайсын теләсәк тә,*
*Әйтер рәхмәтләрнең чиге юк.*
*Туган көнегез белән тәбриклибез,*
*Тормыш күгегез булсын гел аяз.*
*Бәхетләрдән, шатлыклардан гына*
*Торсын сезнең һәр көнегез.*

Шулай ук җәй аенда аларның бергә гомер итә башлауларына 61 ел булды.



*Кушылып үскән куш каеннар кебек*
*Бергә үтә тормыш юлыгыз.*
*Авырлыклар булса, башлар ими*
*Иңне-иңгә куеп узасыз.*
*Яшисез сез, яшәвегез безнең өчен,*
*безнең хакка.*

*Күңелебездә олы сөю, якты уйлар*
*сезнең хакта.*
*Тормышыгыз үрнәк булыр*
*барыбыз өчен һәрвакытта.*
*Яшәгез сез әткәй, әнкәй,*
*Сез бар чакта – без бәхетле бу дөньяда.*

**Иң изге теләкләр белән: балаларыгыз, кияүләрегез, киленнәрегез, оныкларыгыз һәм оныкчыкларыгыз**

## Илдар Динмөхәммәтов:

# “Укытучысы яхшы булса, укучысы аны узар”

«Маяк» кунакханәсе

Ул сәхнә өчен яратылган. Төскыяфәте дә, килеш-килбәте дә, җыргасузгә осталыгы да бик туры килгән. Аны районыбызда белмәгән кеше сирәктер. Мәдәни чараларның күрке ул. 2020 елда Халыкара “Татар сүзе” бәйгесендә лауреат булуы, 2021 елда Әлмәт шәһәрендә узган “Урсал тауда” фестиваль-бәйгесендә “Сәнгатьле уку” номинациясендә гран-при яулавы һәм башка күп кенә җиңүләре дә зур талант иясе икәнлеген раслый. Редакциябезнең әнә шундый асыл кунагы – Илдар Динмөхәммәтов.

***– Илдар Әнсәрович, мондый талант каян килә?***

– Гаиләдән киләдер дим. Әни бик матур җырлый иде, яшь чагында спектакльләрдә уйнаган. Әти бик оста булмаса да, гармун тарткалый, җырлый иде. Алар концертларны яраталар иде. Кечкенәдән җыр-моң арасында үстем.

***– Шуңа күрә һөнәр сайлауда кыенлыклар булмагандыр?***

– Мәктәптән соң армия сафларында хезмәт иттем, аннан кайткач Әлмәтнең техник училищесында һөнәр алып, Азнакайның производствоны автоматлаштыру цехында электромонтер булып эшли башладым. Эштә үзешчән сәнгатьтә актив идем. Сәләтемне күреп, миңа хезмәттәшләрем мәдәният институтына барырга киңәш иттеләр. Читтән торып укырга иде ният, әмма документларны бирергә соңга калганмын, шулай итеп көндез режиссура бүлегендә укып чыктым һәм 1987 елда үземнең туган авылыма – Сәпәй мәдәният йортына директор булып кайттым.

***– Сез бит әле ул чакта татар халык ашларын җитештереп сату буенча гаилә кооперативы оештырып, районны гына түгел, бөтен республиканы шаккатырган идегез...***

– Бик олы бер вакыйга булды инде Татарстан өчен. Эшебез белән танышырга республикадан зур делегация килде.

***– Сезнең ул чактагы гаилә концертлары да истә калган...***

– 1990 елда ике энекәшем белән гаилә концертлары оештырдык, “Таң егетләре” исеме астында җырлый идек. Азнакай–Бакалы районнары арасында узара дуслык күпере салынган елларда Бакалыда, Актаныш һәм башка районнарда, Казанда авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә, Россиянең күп кенә шәһәрләрендә чыгышлар ясадык. Энекәшләр дөньядан иртә киттеләр, урыннары җәннәттә булсын! Бүгенге көндә ике улым белән традицияне дәвам итәбез.

***– Хезмәт юлыгызга карасаң, бик урау булган...***




– Сәпәй мәдәният йортыннан соң ул чакта торак-коммуналь хуҗалыгы җитәкчесе Инсаф Сәитович Солтанов мине үзләренә эшкә чакырды. Балта остасы да, инженер-тәэминатчы да, база җитәкчесе, тулай тораклар директоры булып та эшләргә туры килде. Бирегә 13 ел үзешчән сәнгатьне җитәкләдем, район күләмендә смотр-конкурста 13 ел беренчелекне бирмәдек. Заллар тулы булып, безнең концертларны төнге уникегә кадәр карап утыра иде халык. Бирегә 1997 елда “Таң” ансамбле оештырдык. Концертлар белән тирә-як районнарга йөрдек. 2004 елда мәдәният бүлеге җитәкчесе Азат Гарәфетдинович Галимовның урынбасары итеп билгеләделәр. Шушы чорда Татарстан Мәдәният министрлыгы тарафыннан үткәрелгән “Шаяннартапкырлар мәҗлесе” бәйгесендә зона күләмендә 6 район командасы арасында Азнакайның “Хуҗа кучтәнәчләре” командасы беренче урынны яулады. Зәйдә узган бәйгедә икенче урынга чыктык. Команда капитаны Фирдүс Тямаев иде, ул Хуҗа Насретдинны уйнады. 2007-2009 елларда мәдәният бүлеге җитәкчесе вазифасын башкардым. Аннан тагын бу өлкәдән читләшеп, крестьян-фермер хуҗалыгы оештырып алдым.

***– Авыл егете андый эшне дә батырып башкаргандыр, әмма ничектер Сезне башка юнәлештә күрәсе килми...***

– Район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль эшләр буенча урынбасары Дамир Рашатович Гыйләҗев 2014 елда мине балалар сәнгать мәктәбенә директор итеп димләде. Коллектив ачык йөз белән каршы алды, бик матур эшләдек. Әмма күңелдә күптәнге хыялым йөри иде – театр оештыру. Җитәкчелеккә рәхмәт, каршы килмәделәр, сәнгать мәктәбендә театр классы ачып, рәхәтләнеп укытам. Театрыбызга “Елмай” дип исем куштык. Татарча спектакльләр куябыз. Мәдәният министрлыгыннан Грант отып, ул акчага техника, костюмнар алдык. Канатлар куйган шикелле булды.



***– Шәһәр балаларына татарча уйнау авыр түгелме?***

– Әлбәттә авырлыгы бар. Алар бит мәктәптә дә, өйдә дә русча сөйләшеп өйрәнгән. Кайбер татар сүзләрен бөтенләй аңламыйлар. Текстны ятлап чыгу гына түгел, аңлап сөйләү мөһим. Шуңа күрә русчага тәрҗемә ясарга да туры килә. Конкурсларда жюри дә бала аңлап сөйлиме-юкмы, шуңа игътибар бирә. Татар хәрефләрен дөрес итеп әйтергә өйрәтәм.

***– Репертуар сайлауда кыенлыклар кичерәсезме?***

– Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы мультфильмнарны татарчалаштыру белән шөгыльләнде, шуңа күрә кыенлык күрмим. Без “Винни Пух” спектаклен сәхнәләштердек. Балаларга кызык. Беренче булып Чалпы мәдәният йортында, уку елы азагында гимназиядә чыгыш ясадык. Бик яратып карадылар. Гастрольләрне башка мәктәпләрдә, балалар бакчаларында да дәвам итәргә уйлыйбыз. Мәдәният идарәсе барырга автотранспорт бирә, сәнгать мәктәбе җитәкчелеге дә ярдәм итеп тора.

***– Театрга балаларны ничек сайлап аласыз?***

– Сәләте булмаган баланы да боргатным юк. Андыйлар арасында да күздән яшьләр килерлек итеп шигырь сөйләргә өйрәнгәннәре бар. Укытучысы яхшы булса, укучысы аны узар. Минем өчен баланы шул дәрәҗәдә ача алу зур шатлык. Баланың үз-үзенә ышанычын үстерергә кирәк. Укучыларымның уңышы куандыра. Быелтыр Мәрьям Хәмзина Халыкара “Татар сүзе” бәйгесендә лауреат булды. Безнең театр әле яшь, спектакльләрне яңа куйсәтә, үзебезне таныта башладык.

***– Ике ул үстердек дидегез. Тормыш иптәшегез дә сәнгать кешесеме?***

– Тормыш иптәшем Мөнирә балалар бакчасында шәфкать туташы булып эшли. Сәпәй авылында йорт җиткереп, шунда гомер кичерәбез. Олы улыбыз Илнар гаиләсе белән Азнакайда яши. Кечесе Илназны әле яңа гына өйләндердек, Казанда яши, башка тармакта эшләсә дә, дипломлы җырчы.

***– Мондый сәләтегез белән башкалада тагын да югарырак күтәрелгән булыр идегез. Үкенмисезме?***

– Казанда укыганда укытучылар Г.Камал театрына әзерлибез дигәннәр иде. Әмма туган якка, әти-әни янына нык тартылдым. Һич үкенмим.

***– Сезгә еллар кагылмый кебек. Үзегезне шулай яшь килеш саклауның сере нәрсәдә?***

– Спортны яратам. Азнакайга авылдан эшкә кышын чаңгыда, җәен велосипедта йөрдем. Әти-әнидән килгән геннар да роль уйныйдыр. Аннан соң мин – оптимист, эчкерсез кеше, бөтен әйбергә сөенеп, ямь табып яшәү сәләтен сакладым. Балалар белән эшләү дә яшәртә торгандыр. Кешеләрне, дөньяны, тормышны яратам. Райондашларны 30 сентябрьдә Мәдәният йортында узачак иҗат кичәмә көтеп калам.

***– Әңгәмәгез өчен рәхмәт, алга таба да уңышлар Сезгә!***

«Маяк»
Җомга №69 (13648) |23 сентябрь 2022 ел

Яңалыкларны aznakaevo-rt.ru
сайтында һәм социаль челтәрдәге
төркемнәребездә укыгыз

# Очрашу күңелле узды

Редакция почтасыннан

**Җәй – төрле бәйрәмнәргә бай ел фасылы. Сабантуйлар, урам бәйрәмнәре, һөнәри бәйрәмнәр һәм, әлбәттә инде, сыйныфташлар очрашуы...**



Шундый очрашуларның берсе Урсай сигезьеллык мәктәбенең 1975 елгы чыгарылыш сыйныф укучылары арасында да булды. Очрашуга 16 кеше килгән иде. Кызганычка каршы, 6 сыйныфташыбыз бакыйлыкка күчте инде. Очрашу урыны классташыбыз, дустыбыз Гөлүсә Гарифуллина һәм тормыш иптәше Илмир ишек алдында узды. Түбән Кама шәһәрендә хезмәт юлы үтеп, лаеклы ялга туган авылларына яшәргә кайткан бу парның ишек аллары оҗмах бакчаларын хәтерләтә. Шулай дими мөмкин дә түгел. Ямь-яшел чирәм түшәлгән, бассейн, фонтан, сиртмәле кое, жил тегермәне, беседкасы булган, алма-чияләре сыгылып утырган чәчәкле ишек алдына килеп кергәч, үзеңне оҗмах бакчасына эләккәндәй хис итәсең. Сыйнигъмәтләр белән сыгылып утырган табын артында сыйныфташыбыз Әминә бакыйлыкка күчкәннәр хөрмәтенә дога укыды, һәрбер кеше үз тормышы турында сөйләде, укытучыларыбыз, мәктәп еллары белән бәйле яшьлек хатирәләре искә алынды, Заһир Әмиржановның гармун моңнарына кушылып, җырлар башкарылды. Рәхәт мизгелләр бүләк иткән очрашудан хуҗаларга, оештыруда аерата активлык күрсәткән сыйныфташларыбызга рәхмәт әйтеп таралыштык. Юкка гына: «Бер очрашу – бер гомер», – димиләр бит. Без дә, 62 еллык гомеребезне хәтердән үткәреп, өлкән яшьтә булсак та, күңелләребезнең әле мәктәп елларындагыдай яшь икәненә инанып аерылыштык.

**Халидә Нургалиева,**
**Тымытык авылы**

# Гадәти булмаган көрәш

*(Уены-чыны бергә)*

Мин эштән кайтып кергәндә, веранда өчен барган сугышның иң кызган чагы иде. Хатынның зеленка белән буялган иягенә, аска таба салынып төшкән сул як битенә караганда, бу бәрелешнең бик тә аяусыз булганы күренеп тора. Инде шактый гына тән җәрәхәтләре алган, тик бирешергә уйлап та карамаган җанкисәгемнең дошманнарына нәфрәт белән тулы күзләре очкыннар чәчеп тора. Верандага хуҗа булырга теләгән шөпшәләрнең дә, араларында инде шактый гына корбаннар булуына карамастан, җиңелергә исәпләрендә дә юк. Үзләрен әллә кемгә куеп, минем җәмәгатемә игътибар да итмәгән кыяфәт чыгарып, оя коруларын дәвам итәләр. Ул шөпшәләр шулкадәр күп, әйтерсең лә бөтен авылдагы кардәшләрен дә монда өмәгә чакырганнар. “Безнең кыз кияү күргән мени” дигән сыман, моңа кадәр шөпшә күрмәгән минем җәмәгатем дә күп уйлап тормаган, иң зур себеркесен алып, аларны верандадан куып чыгара башлаган. Моның инде нинди нәтиҗәгә китерүен менә шушы үзенчәлекле кыяфәте күрсәтеп тора. “Синең белмәгән нәрсәң юк, бу шөпшәләрдән котылуның да берәр җаен тап” – дип, хәзер инде миңа мәсьәләне каты куйды җанкисәгем. Тормыш тәҗрибәм шактый булса да, шөпшәләргә каршы бер тапкыр да сугышып караганым булмады. Бары тик аларны себерке белән куып кына җиңеп була алмаганын бик үк акылы булмаган кеше дә белергә тиештер дип исәпләсәм дә, ул турыда хатынга әйтеп торуны кирәк тапмадым.

Шушы минуттан башлап, бу сугышның стратегиясен төзергә җаваплы кеше итеп мин билгеләндем. Стенадагы шөпшә оясына карап, төрле ысулларны куллану турында фикер йөртеп карасам да, ныклы карарга килә алмадым. Ә ул оя вакыт узган саен, күз алдында ук шактый гына үсеп, һаман да зураеп бара. Интернетны актарсаң, анда меңәрләгән вариантлар язылган: бер җирдә шөпшәләр белән дус яшәп тә була дигән, икенчесендә ут төртеп яндырырга кушкан. Минем очракта боларның берсе дә туры килми, шулай да аш серкәсе сипсәң шөпшәләр качып китәләр икән дигән киңәшне кулланып карарга булдым. Тәрәзәнең форточкасын зур итеп ачып куйдым да, шул сыекчаны шприц белән тегеләрнең ояларына җибәрдем. Бу шөпшәләр өчен үзенә күрә бер котылу чарасы иде, чөнки инде бүтән чара күрмәгән җәмәгатем ике дихлофос баллоны тотып кайтып керде. “Җанкисәгем тынычлан” – мин әйтәм, “ике сәгатьтән монда бер җан иясе дә калмый” – дим. Бәхеткә, бүген кичке бәйрәм тантанасында Фирдүс Тямаев җырларга тиеш, шөпшәләргә капитуляциягә мөмкинлек биреп, шул чарага киттек.

Фирдүс концертын гомумән тыныч кына утырып карап буламы соң инде ул. Шуңа күрә сәхнә каршындагы меңләгән халык арасына бастык та, таныш һәм таныш булмаган кешеләр белән Фирдүскә кушылып, аның үзеннән дә катырак итеп акырып, рәхәтләнеп биедек. Бик күңелле булды алай, әле җәмәгатем кайтканда да Фирдүснең сандугачмы, торнамы турындагы җырын кабатлый-кабатлый куллары белән машинаның алгы панелена бәргәләп кайтты. Сүз әйтмәдем инде, теге шөпшәләр турында гына онытсын да беraз тынычлансын дидем. Әйе, онытты ди монда, Данир Сабиров бит тиккә генә: “Фирдүс Тямаевның концертын караганнан соң, берәрсен тотып тукмыйсы килә башлый”, – дип әйтмәгәндер. Җанкисәгем кайтып керү белән верандының ишеген каерып ачып ташлады да, Фирдүснең: “...яшәп калыйк, янып калыйк...” – дигән җыр сүзләрен кабатлый-кабатлый бар көченә дихлофос сиптерә башлады. Боевиктагы Рембо сыман, нинди дер нәфрәт катыш тантана белән, соңгы патронына, ә юк, соңгы тамчы агуына кадәр сиптереп бетерде дә, бушаган баллонны почмакка атып бәрде. Минем аңлавымча, бу верандадагы шөпшәләрнең соңгы сәгатьләре һәм берничә көнгә сузылган көрәшнең соңгы көне иде.

Җәмәгатем тыныч күңел белән йокларга ятты. Аның йокы аралаш берничә тапкыр: “Мишәрләр, вперед!” – дип кычкырып куюын исәпләмәгәндә, төн тыныч кына узды. Иртән яктырыла башлауга, йокының иң тәмле чагында моңа кадәр таныш булмаган ниндидер билгесез бер җан иясе төртеп уятты мине. Башына берничә яулык ураган, битенә төсе нинди икәне аңлашылып бетмәгән чүпрәк бәйләгән бу әйбер кайсы ягы беләндер рәсемдәге чалгы күтәреп килүче үлемгә охшаган иде. Тик бу бүлмәләрне бутаган ахры: “Син бит шөпшәләр янына килгәнсеңдер, ә алар верандада, бөтен идәнне тутырып сине көтеп яталардыр. Әле минем үләргә исәбемдә дә юк, пенсиягә чыгып та бераз яшисе, хөкүмәттән дә әз генә булса да файда күрәсе килгән иде”. Шулвакыт теге чүпрәк уралган башның авыз булырга тиешле урынынннан ишетелгән: “Әйдә, таң аткачы теге шөпшәләрнең ояларын бәреп төшерик”, – дигән тавыш җанкисәгемнекенә охшаган иде. Шунда гына минем каршымда басып торган теге куркыныч әйбернең, бер тапкыр шөпшәләр талаганнан соң шулай итеп киенгән җәмәгатем икәнлеген аңладым. Саклану чарасы идеме ул, әллә шушы кыяфәте белән шөпшәләрне куркытырга теләгәнме, шунысы гына аңлашылмады. Мин исән калу шатлыгыннан күп уйлап тормадым, тиз генә көрәк алып кереп, шөпшәләрнең ояларын бәреп төшердем дә, йокыны дәвам итәргә дип өйгә кереп киттем. Ә хатыным икенче баллон дихлофосны эшкә җикте.

Без уянып киткәндә кояш югары күтәрелгән иде инде. Тик безне әтәч тавышы түгел, шөпшәләрнең гөжләве уятты. Веранданың ишеген ачып карасак шаккаттык, иртәнгә инде юк булырга тиешле шөпшәләр үлеп кенә калмаганнар, ә берничә тапкыр арткаппар да. Әле теге ояны бәреп төшергәннән соң күренгән стенадагы тишектән чыкканнары тагын да өстәлеп торалар. Әһә, имәндә икән бит монда чикләвек. Шөпшәләрнең төп оялары веранда стенасының ике тактасы артында булып, юка гына тактаны тишеп бу якка чыкканнар икән. Ә без оя дип уйлаган әйбер, шул “тулай торакның” “балконы” гына булып чыга. Шулай ук урам ягыннан кереп-чыгып йөрер өчен дә тишек ясаганнар. Без агу сиптергән саен шөпшәләр тишектән кереп китеп, урам ягына чыгып саф һавада йөреп киләләр дә, бүлмә җиллләгәч кире кайталар икән. Димәк без берничә көн шул шөпшә оясының “балконы” белән көрәшкәнбез. Мин аларның күпләп ояларына кереп киткәнен көтеп тордым да, стенаның шул өлешен калай белән каплап куйдым. Ямап кына түгел, ә почмакларын матурлап, тигез итеп ясадым, үзенә күрә евроремонт булды бу. Ояларында бик тә ямьле итеп гөжләшәләр әле безнең шөпшәләр, веранда ягына чыга алмауларына гына эчләре поша бугай. Үз-үзләрен тотышларына караганда, шунда кышларга җыеналар ахрысы болар. Ә нигә, урыннары җылы, әйбәт, тик оялары гына балконсыз була инде хәзер. Урам ягына да евроремонт ясап, теге үзем җимергән балкон урынына икенчене ясап куярга минем әлегә вакытым юк. Бик кирәк дип тапсалар ясасыннар үзләре, мин каршы түгел. Менә шулай яшәп ятабыз хәзер, беркем беркемгә комачауламый, һәркемнең үз йорты, үз мәшәкатьләре. Ә бер караганда дөнья киң бит ул, урын барыбызга да җитә. Яшик әле шулай тату гына, матур гына гөрләшеп һәм гөжләшеп, тик һәркем үзенең өендә.

**Марат Исхаков**

Реклама

**САТЫЛА**

1334 Автомобиль Шевроле 2017г. выпуска Тел. 8-917-267-26-02.

1351 1-комнатная квартира в г.Казани. Тел. 8-917-289-43-88, 8-960-07-63-73

1365 2-комнатная квартира в пгт.Актюбинский. Тел. 8-917-866-08-56.

1319 Тымытык авылында кирпеч йорт. Тел. 8-917-862-88-11.

1309 Дом д.Карамалы. Тел. 8-917-906-68-20.

1347 Какре Елга авылында йорт. Тел. 8-965-615-66-48.

1371 Мөслим районы Түбән Табык авылында яхшы йорт. Бәясе килешү буенча.Тел. 8-927-043-20-86, 7-83-97 (Азнакай).

1277 Тавык, бройлер, үрдәк, мулард, каз бәбкәләре. Китерәбез. Тел. 8-960-077-65-76, 8-987-419-38-11.

1201 Бройлер, кызыл тавык, мулард, каз, үрдәк. Тел. 8-917-936-12-84.

1249 Утки, бройлеры. Тел. 8-939-363-19-73.

1301 Суя торган бройлерлар, тавыклар. Тел. 8-917-392-56-69 – Рәмилә.

1349 Бройлеры 23 сентября 1 мес. Муслюмовский район, с.Митряево. Тел. 8-917-867-04-29 Ильнур.

1345 Бычки и телята симментальской породы. Тел. 8-939-31-10-273, 8-939-33-89-820.

**САТЫП АЛАМ**

1370 Итләтә һәм терелэй мал. Тел. 8917-435-41-04.

979 Закупаю мясо дорого. Тел. 8-929-758-83-42, 8-917-443-69-97.

58 Мясо говяжье (коровы, быки). Тел. 8-927-966-55-53.

1023 Авто дорого. В любом состоянии. Тел. 8-917-272-21-77.

1135 Ит, мал. Төрлесеннән. Тел. 8-927-348-03-34.

1134 Выкуп любого авто. Тел. 8-919-692-93-21.

1259 КРС (быки коровы, телки живьем). Тел. 8-927-237-31-49.

**ХЕЗМӘТЛӘР**

1131 Ремонт стиральных машин на дому. Тел. 8-919-695-65-91.

1178 Натяжные потолки. Тел. 8-917-278-40-58 – Ильнур.

1276 Натяжные потолки. Рулонные шторы. Тел. 8-917-851-81-96.

1280 Ремонт телевизоров. Тел. 8-927-458-38-65.

1275 Ремонт крыш гаражей. Тел. 8-917-918-8-917

1221 Диваннар тышлыйбыз. Тел. 8-917-873-82-53.

106 Обшиваем, ремонтируем мягкую мебель. Качественно, с гарантией. Тел. 8-905-372-01-42.

1273 «КамАЗ», песок, щебень, навоз. Тел. 8-919-631-87-14, 8-917-247-56-43.

1147 Грузоперевозки. Тел. 8-937-612-42-62 – Марат.

**1266 Компьютерные услуги. Тел. 8-917-930-95-20.**

**1188 Откачка ям и канализации. Тел. 8-917-898-06-05, 8-927-480-30-61.**

1235 Срочный ремонт стиральных машин, холодильников. Стаж имеется. Гарантия Обязательна. Тел. 8-927-424-19-18.

1281 Откачка канализации. Тел. 8-987-273-34-40, 8-987-220-63-88.

1288 ПГС, песок, щебень, перегной, чернозем. Тел. 8-987-293-44-97.

**1335 Срочный ремонт холодильников. Гарантия. Тел. 8-987-005-83-23.**

1298 Выполняем любые строительные работы. Тел. 8-917-924-56-05.

1350 Ремонт пластиковых окон. Тел. 8-917-289-90-00

**АРЕНДА**

1373 1-комнатную. Тел. 8-917-228-60-34.

**ТЕПЛИЦЫ**
**ЗАВОДСКИЕ** 1360 Реклама
- УСИЛЕННЫЙ ОЦИНКОВАННЫЙ КАРКАС
- ДВЕ ДВЕРИ, ДВЕ ФОРТОЧКИ
- ПОЛИКАРБОНАТ 4 ММ, С УФ-ЗАЩИТОЙ
- БЕСПЛАТНАЯ ДОСТАВКА И УСТАНОВКА. ГАРАНТИЯ

**8 927 348 24 30**

1203 **Наличники
на окна
из цветного металла.**
Низкие цены. Рассрочка.
**Тел. 8-927-43-53-542,
8-904-66-77-265.**
Реклама

1225 Подъем углов и укрепление фундамента старых домов. Выравнивание кривых полов. Разбор сеновалов и др. работы. **Тел. 8-919-146-01-25, 8-937-34-22-740.** Реклама

1348 **27 сентября 2022 года в пгт. Актюбинский с 9 до 16 часов**

Ярмарка верхней одежды «Княжна».

Большой выбор верхней одежды, эко шубы, дубленки, двухсторонние пуховики, куртки!

Рассрочка без переплаты!**

Реклама

8-987-163-39-30

**Подробности у продавцов в день продажи 27 сентября 2022 года.*

**Скидки и рассрочку предоставляет ИП Николаева Любовь Ивановна*

*ИП Николаева Любовь Ивановна ОГРНИ ИП 318595800088379*

Иҗат - гүзәл гамь ул, иң югары дәрәҗәдәге изге тынгысызлык ул. Иҗат ике канатлы ул: яхшыны исбат итү, яманны инкар итү ул, яхшылыкка мәхәббәт, яманлыкка нәфрәт ул! *(Хәсән Туфан)*

Бәхеткә теләкләрнең артык күплеге һәм аларның бөтенесен канәгатьләндерергә теләү комачаулый. *(Артуро Граф)*

# Ат иярләгән кыз

Хикәя

Резеда **ШӘРИПОВА**

**Бу җәйдә Маратны авылга әбисе янына кайтардылар. Моңа кадәр каникулларны ял лагерында үткәрә иде ул. “Хәзер син зур инде, әбиеңә ярдәм итәрсең”, – диделәр.**

Үндүртенче яшен тутыра Марат. Быел буйга да сузылып китте. Үзенең дә бала-чага арасына бик барасы килеп тормый иде. Әмма авылда да кызык тапмый аптырап йөрде. Интернет юньләп тотмый, телевизордан берничә генә канал күрсәтә. Аралашырга күрше-тирәдә ишләре дә юк. Сарайда бабасыннан калган кармакларны күргәч кенә кызыклы шөгыль тапты ул. Кечкенәрәк чакта бабасы белән елга буена төшкәли иде Марат, аның өйрәткәннәре күңелендә сакланган икән.

Балык шәп чиртә торган урынга да юлыкты. Үзән буйлап бормаланып аккан елганың бер ышык култыгында кызылканатларны чүпләп кенә өлгер!

Бүген елганың тынычлыгын җирән чәчле бер кызый бозды. Чәче төсле җирән атка атланган чандыр гәүдәле кыз Мараттан ерак түгел генә җирдә елганың сайрак турына керде дә, яшен тизлегендә ияргән сикереп төште. Ул атын иркәләп-назлап сыпырды, су эчкәнен көтте, аннан аны юарга кереште. Кыз Маратны искәргәндермәкюкмы, әмма аның ягына әйләнеп карамады. Озак юанмадылар, ничек юыртып килгән булсалар, шулай китеп тә бардылар.

Авыл кызлары атта йөридер дип уйламый иде Марат. Үзе яшендәге кызның шулай оста җилдерүенә сокланып калды ул.

Икенче көнне дә кыз нәкъ шул вакытта, нәкъ шул урынга ат коендырырга төште. Бу юлысы Марат аның белән танышырга теләп, чүгәләгән җиреннән тураеп, сүз катты:

– Атың матур!

Әмма кыз аңа гамьсез карашын ташлап алды да, берни эндәшмәде.

– Шәп йөрисең! – дип тагын мактау юллады егет.

Бу юлы кыз күтәрелеп тә кармады.

“Тәкәббер!” – дип уйлады Марат.

Кызның кыланмышы күңелен үрсәләндерде. Аның җирән чәчле бу кыз белән танышасы, аралашасы килгән иде. Бәлкем әле атта йөрү бәхете тә елмайган булыр иде.

Бар кыюлыгын җигеп, ул кыз ягына юнәлде. Әмма аның якынайгынын күреп, кыз җәһәт кенә атына сикереп менде дә китеп барды.

“Кырагай!” – дип үзаладына ачулы итеп әйтеп салды Марат.

Аңарда балык кайгысы калмады, кызлытүшләргә кул селтәп, өенә кайтып китте.

– Бик вакытлы, улым, әйдә, өчпочмаклар яңа табадан төште, – дип каршылады әбисе елмаеп.

Ул гел елмаеп кына йөри. Ачулы чагын Маратның бер дә күргәне юк. Онысын ниләр белән генә сыйламый! Таба исе борынны кытыклап, ашказанын уятты. Яр буенда шактый утырып ачыгылган икән, Марат күз ачып йомганчы ике өчпомакны ялтыратып куйды.

Теге җирән чәчле кыз ашаганда да күз алдыннан китмәде.

– Әби, авылда атлар бармы? – дип читләтеп башлады ул соравын.

– Бар дип, Әхмәтләрдә генә бугай инде. Анысын да кызы өчен тота.

– Нигә кызы өчен генә?

– Алсу тумыштан ишетми дә, сөйләшми дә. Әхмәт ат белән колхоз малларын көтә иде. Алсу кечкенәдән Җирәнкәйгә бәйләнде. Колын чагыннан ук бергә алар. Колхоз таралгач, Әхмәт абыең Җирәнкәйне кызына дип сатып алды. Алсу шәһәрдә интернатта торып укый, ялларын авылда, гел аты янында...

Менә ни өчен сәлам бирмәгән икән ул Маратка. Ә ул, юләр, әллә ниләр уйлап бетерде!

Ул төнне ул төшендә Алсуны күрде. Алар Марат белән елгада ат коендырдылар, аннан яланнарны иңләп Җирәнкәйдә чаптылар. Шундый матур, татлы төш иде...

1364 Кадастровым инженером Файзуллиной Гульзирой Рауфовной ( квалифицированный аттестат кадастрового инженера №16-11-380; почтовый адрес: 433332, республика Татарстан, г.Азнакаево, ул. Тукая, д.7, кв.13, электронная почта: Faizullina1962@bk.ru.тел.:+79172560643, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность:14904) подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемой в счет земельной доли Халиловой Миннеасмы Нуретдиновны из земельного участка с кадастровым номером 16:02:000000:862, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Азнакаевский муниципальный район, на территории Урсаевского сельского поселения.


Заказчиком работ является Файзуллина Гульзира Рауфовна, зарегистрированная по адресу: РТ, Азнакаевский район, г. Азнакаево, ул. Тукая, д.7, кв.13, тел.: +7 917 256 06 43.

С проектом межевания земельных участков можно ознакомиться с 8.00 до 17.00 часов, кроме субботы и воскресенья по адресу: РТ, г.Азнакаево, ул. Гагарина, д.6, 2 этаж, кабинет 27 А.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.*

*п.8, п.11 ст.13.1 Федерального закона от 24.07.2002г №101-ФЗ «Об обороте земель сельскохозяйственного назначения».

## Сатуга яңа китап кайтты




“Маяк” газетасы редакциясенә сатуга язучы Рафис Корбанның яңа гына табадан төшкән “Тәүбә көне” китабы кайтты.

Соңгы елларда проза жанрында актив иҗат итүче Рафис Корбанның бу китабына кергән “Тәүбә көне” һәм “Бер уч туфрак” повестьларында хәзерге заманда адәм балаларының рухи тормышына кагылышлы гыйбрәтле хәлләр тасвирлана. Дөнья куып яшәүче замана кешеләре үзләренең әдәп-әхлагы, рухияте турында уйланамы? Аталар һәм уллар бер-берсе белән үзара аңлашып яшиме? Язучы геройларын гадәттән тыш вакыйгалар яктылыгында сурәтләп, үзе яшәгән чорга бәя бирә.

***Китап күзге салкын кичләрдә җаныгызга, һичшиксез, җылы бирер!***


***Алыгыз, рәхәтләнеп укыгыз!***

Телефон: 9-39-80. *Реклама 12+*

## *Якыннарыгызны видеокотлау белән шатландырыгыз!*

Әти-әниегез, туганыгыз, күршегез яки хезмәттәшегезнең туган көнеме? Әйдәгез, көтелмәгән бүләк ясап, аларга видеокотлау аша иң изге, җылы теләкләребезне җиткерик!

Үз эченә сез тәкъдим иткән фотоларны да алган видеокотлау рәсми сайтыбызда урнаштырылачак, аны социаль челтәрләр аша тарату мөмкинлеге дә бар. Иң мөһиме, якыннарыгызны сез көнендә котлап, аларны сөендерә аласыз! Газетага язылучыларга ташламалар да каралган.



**Белешмәләр өчен телефон: 9-39-80.** *Реклама*

1311
**ОКНА МЕЧТЫ**
**ОКНА БАЛКОНЫ**
VEKA Века
HÖRMANN Хорман
SALAMANDER Саламандер
ООО «АЙКАПРО» ОГРН 1211600016924 ИНН 1650399916
**8 939 393 48 48**
Реклама

907
**БЕТОН**
От производителя в г. Азнакаево
**тел: 8-919-642-44-45**
РЕКЛАМА

1312 **Салон памятников «МИР КАМНЯ»**
Памятники на могилы.
Уход за могилой
Ограды любой сложности.
Установка производится до поздней осени.
Действует система скидок.
***Адрес: г.Азнакаево, ул.Гагарина, 33 А.***
**Тел. 8-986-909-46-62.**
Зиганшин Ильдар Сайринович, ИНН 164201554208. Реклама

1295 **В организацию ООО «СТК КЕДР» ТРЕБУЮТСЯ:**
- МЕНЕДЖЕР ПО ПРОДАЖАМ
- СНАБЖЕНЕЦ
- ИНЖЕНЕР-ТЕХНОЛОГ
- СВАРЩИКИ
- СЛЕСАРИ И ОТДЕЛОЧНИКИ
- МАЛЯР ПО МЕТАЛЛОКОНСТРУКЦИЯМ.

**Тел. 8-987-208-03-00.**
*Реклама*

Парус
1153
**ТЕПЛИЦЫ ПОЛИКАРБОНАТ**
БЕСЕДКИ.ЗАВОДСКОЕ КАЧЕСТВО. НИЗКИЕ ЦЕНЫ.
**8-906-333-70-63**
*ПОДРОБНОСТИ ПО ТЕЛЕФОНУ
ИП ШАРУНИН АЛЕКСАНДР АЛЕКСАНДРОВИЧ ОГРН ИП 312168903400034
РЕКЛАМА

**8-963-902-0000** http://okna-bahetle.ru
Реклама
1262
**ОКНА «Бәхетле»**
5 -ое окно в подарок*
ОГРН 1160280118591
- Расширение оконного проема
- Установка откосов
- Рулонные шторы
- Алюминиевые конструкции

скидка до 30%**
Отлив, подоконник, москитная сетка В ПОДАРОК!!!*
А так же изготовление 3-D металлических откосов!!!
**РАССРОЧКА** ** **БЕЗ УЧАСТИЯ БАНКА**
**Рассрочку и скидку предоставляет ООО «Бәхетле»
*Подробности у продавцов в офисах продаж

1265 ***Магазин «Двери» на оптовой базе***
предлагает вашему вниманию:
**НОВИНКИ межкомнатных дверей, замки, ручки, петли (по оптовым ценам.)**
Монтажная пена.
Все виды уплотнителей.
Магазин «Двери» на оптовой базе.
**Тел. 8-960-076-90-04.**
ИП Хасанова Елена Мирсаяфовна, ОГРН 312168819500040
Реклама

**НАЛИЧНИКИ НА ОКНА**
От 2500 руб.
Пенсионерам скидки* и подарки
РАССРОЧКА!*
* Скидку и рассрочку предоставляет ИП Фаздалова А.Г.
1340
*ЗАМЕР И УСТАНОВКА - БЕСПЛАТНО!*
8-939-733-93-77, 8-953-498-21-87 Рамиль
Реклама


Комсызлык белән бәхетнең очрашканнары юк. Алар бер-берсен белмиләр. *(Бенджамин Франклин)*

Башкалар өчен якты нур булу-кеше ирешә алырлык иң зур бәхет. Ул чакта аны бернинди газап та, әрнү дә, кайгы-хәсрәт тә, мохтаҗлык та куркытмый. *(Феликс Дзержинский)*









## Сливадан джем

Аш-су

Сливаны юып, әзрәк су салып кайнатып чыгарырга. Артык суын сөзеп алырга. Суынгач, иләк аша чыгарып, шикәр комы кушып, кайнап чыгу дәрәҗәсенә җиткәч сүндерергә һәм кайнар килеш банкаларга тутырырга.

Артык суын сок итеп ябарга мөмкин.



Гамәлгә куючы – “ТАТМЕДИА” АҖ
**www.aznakaevo-rt.ru**
Реклама хезмәте телефоны: 8(85592)9–39–80

МАЯК
Азнакай муниципаль районы газетасы
“ТАТМЕДИА” АҖ филиалы директоры - баш мөхәррир
Ф.Ф.Шәйхулов

Редакция адресы:
423330, Азнакай шәһәре, М.Хәсәнов ур., 12
Электрон адрес: azmayak@ mail.ru
Сайт адресы:*www.aznakaevo-rt.ru*
Телефоннар:
9–43–57- кабул итү бүлмәсе,
9–39–80- реклама бүлеге, факс.
Нәшер итүче: “ТАТМЕДИА” АҖ
420097, Казан шәһәре, Академик ур, 2.

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2013 елның 16 маенда ПИ № ТУ16-01015 нче таныклык белән теркәлде
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы “Идел-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
Газетаны басарга график буенча 14.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш, фактта - 14.00 сәгатьтә кул куелды.

ТМ
Тираж - 3526 данә.
"Татмедиа" республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән оештырылды

Редакция фикере һәрвакытта авторлар фикере белән туры килми.
Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк.
Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт

Газета чәршәмбе, җомга көннәрендә чыга.
Заказ №7126
Газетага язылу индекслары:
физик затлар өчен – 00050;
оешма-предприятиеләр өчен – 00051.
Сату бәясе ирекле.
16+